СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**31 март, 2026 ел** **№ 66**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 03 октябрендәге 207 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 1743 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Бөреле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2026 елның 17 февралендәге 277/о номерлы боерыгын раслауга бәйле рәвештә, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 03 октябрендәге 207 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына Федераль дәүләт территориаль планлаштыру мәгълүмат системасының рәсми сайтында мәгълүматны актуальләштерүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып

игълан итәргә (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Совет рәисе урынбасары,
муниципаль район Башлыгы урынбасары Ә.Ш.Шакиров